БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» 03 2026 ел № 142

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча
2026 елның I кварталына гомуми торак мәйданының
бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе субъектларына торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм» федераль проектының яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чарасын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» региональ проектын гамәлгә ашыру максатларында, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» НП (коммерциячел булмаган) эксперт-консультация советының 2026 елның 13 январендагы 01-35/25 номерлы хаты һәм Балтач муниципаль районы торак комиссиясенең 2026 елның 17 мартындагы 4 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районы территориясендә «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2026 - 2030 елларга яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2026 елнын I кварталына гомуми торак мәйданынын бер квадрат метры бәясен 65 593,5 сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов